КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 июль г.Казань № 588

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче; 2016 ел, 26 июль, 508 нче; 2016 ел, 19 август, 575 нче; 2017 ел, 10 ноябрь, 859 нчы; 2018 ел, 10 май, 340 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 нче пунктта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

1.4 нче пунктта «учреждениеләрнең» сүзен «оешмаларның» сүзенә алыштырырга;

3.3.2 нче пунктның дүртенче абзацында «учреждениеләрдә» сүзен «оешмаларда» сүзенә алыштырырга;

3.3.8 нче пунктта «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алыштырырга;

3.3.11 нче пунктның җиденче абзацында «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алыштырырга;

3.3.12 нче пунктның дүртенче абзацында «учреждениеләрне» сүзен «оешмаларны» сүзенә алыштырырга;

3.3.16 нчы пунктта «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алыштырырга;

3.3.23 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.23. Ветеринария өлкәсендә эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче, Россия Федерациясенең Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булмаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәүне гамәлгә ашыра.»;

3.3.24 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.24. Ветеринария өлкәсендә эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче, Россия Федерациясенең Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булмаган ветеринария өлкәсендәге белгечләр эшчәнлеген тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.»;

4.1 нче пунктта:

унынчы абзацта «учреждениеләргә» сүзен «оешмаларга» сүзенә алыштырырга;

уникенче абзацта «предприятиеләре һәм учреждениеләре» сүзләрен «оешмалары» сүзенә алыштырырга;

5.2 нче пунктта:

унынчы абзацта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

ундүртенче абзацта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

унбишенче абзацта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

уналтынчы абзацта «учреждениеләрнең» сүзен «оешмаларның» сүзенә алыштырырга;

унтугызынчы абзацта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

утызынчы абзацта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

6.1 нче пунктта «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алыштырырга;

6.2 нче пунктта «учреждениеләренә» сүзен «оешмаларына» сүзенә алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 ел, 16 август, 563 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 968 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә, 5 нче пункттагы «учреждениеләрен» сүзен «оешмаларын» сүзенә алыштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен, хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алу нәтиҗәсендә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннардан эшләнгән продуктлар һәм чималны эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмәне һәм хайваннарның аеруча куркыныч авыруларында хайваннарны һәм терлекчелек продукциясен алу тәртибе хакында

аңлатманы раслау турында» 2002 ел, 29 гыйнвар, 38 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү тәртибендә:

7 нче пунктның 4 нче пунктчасы үз көчен югалткан дип санарга;

8 нче пунктта «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алу нәтиҗәсендә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплау тәртибенең 2 нче пунктында «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алыштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада «ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениесенең» сүзләрен «ведомство буйсынуындагы дәүләт оешмасының» сүзләренә алыштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2005 ел, 20 апрель, 192 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 7 июнь, 251 нче; 2006 ел, 24 апрель, 209 нчы; 2006 ел, 15 июнь, 308 нче; 2007 ел, 5 февраль, 35 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2014 ел, 13 февраль, 83 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 нче пунктның икенче абзацында «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алыштырып, үзгәреш кертергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2005 ел, 21 гыйнвар, 18 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе ведомствосы буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре ихтыяҗлары өчен заказлар урнаштыруны оештыру тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 10 декабрь, 1031 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин